# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Административ хокук бозулар турында**
**Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 23 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында 2006 елның 19 декабрендәге 80-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3; Ватаным Татарстан, 2010, 29 июнь, 7 июль, 17 июль, 4 август) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 3.11 статья өстәргә:

“3.11 статья. **Балаларның сәламәтлегенә һәм аларның үсешенә зыян китерүне кисәтү чараларын тәэмин итү таләпләрен үтәмәү**

Балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чараларын тәэмин итүнең Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән таләпләрен үтәмәгән өчен –

кисәтү ясала яисә гражданнарга – биш йөздән алып бер мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – өч меңнән алып биш мең сумга кадәр; юридик затларга унбиш меңнән алып егерме мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.

Шул ук гамәлләрне ел дәвамында кабат кылган өчен –

гражданнарга – ике мең сум; вазыйфаи затларга – унбиш мең сум; юридик затларга илле мең сум күләмендә административ штраф салына.”;

2) 7 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 7.8 статья өстәргә:

“7.8 статья. **Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре**

Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре әлеге Кодексның 3.11 статьясында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләрне карыйлар.”;

3) 8.1 статьяның икенче өлешенә “3.10 (гражданнарга карата)” сүзләреннән соң “, 3.11” санын өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 14 октябре
№ 65-ТРЗ